ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**12 декабрь 2022 ел**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 3400**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районының хисапчы хезмәтләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 23 апрелендәге 962 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 02 октябрендәге 1894 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләр белән)

Хисапчы хезмәтләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын камилләштерү максатыннан, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районының хисапчы хезмәтләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 23 апрелендәге 962 номерлы карарына (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 02 октябрендәге 1894 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 23 апрелендәге 962 номерлы карарына 1 нче кушымтаны, «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-икътисад хезмәте» муниципаль казна учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында нигезләмәнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ЗМР БК финанс-икътисади хезмәте» МКУ хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Хезмәткәр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум |
|---|---|
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 31 800 |
| Муниципаль учреждение җитәкче урынбасары | 30 200 |
| Бүлек начальнигы | 24 500 |
| Бүлек начальнигы урынбасары | 21 000 |
| Әйдәп баручы хисапчы | 20 800 |
| Әйдәп баручы икътисадчы | 20 800 |
| Сатып алулар өлкәсендә әйдәп баручы белгеч | 20 800 |
| Әйдәп баручы ревизор | 20 800 |
| Хисапчы | 19 300 |

| | |
|---|---|
| План-техник бүлеге белгече | 19 300 |
| Ревизор | 19 300 |
| Сатып алулар өлкәсендә белгеч | 19 300»; |

1.2.Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 23 апрелендәге 962 номерлы карарына 1 нче кушымтаны, «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-икътисад хезмәте» муниципаль казна учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында нигезләмәнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хисапчыларның вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Муниципаль берәмлектә халык саны | Вазыйфаның исеме, оклад (сум) | |
|---|---|---|
| | Баш хисапчы | Хисапчы |
| 3,5 меңгә кадәр кеше | 19 700 | |
| 3,5 меңнән артык кеше | 21 000 | |
| 1,9 меңнән артык кеше | | 18 500»; |

2. Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы бухгалтерлык хезмәтләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 23 апрелендәге 962 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 2 октябрендәге 1894 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (htpp:/pravotatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ЗМР БК җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В.Старостин